# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге составына керүче Урсай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**20.11.2020** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 14нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: "Сез 2020 елда Урсай авыл җирлегенең Урсай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- скважинадан су башнясына кадәр суүткәргеч торбалар урнаштыру, янгын гидрантларын суүткәргеч линиягә тоташтыру;
- янгын сүндерү җиһазлары һәм инвентарь сатып алу;
- торак пункт эчендәге юлларны төзекләндерү;
- чишмәне төзекләндерү

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 228 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 135 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 120 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 15 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныйрга, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.
2. Түбәндәге сорау буенча карар кабул итәргә: «Сез 2020 елда Урсай авыл җирлегенең Урсай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- скважинадан су башнясына кадәр суүткәргеч торбалар урнаштыру, янгын гидрантларын суүткәргеч линиягә тоташтыру;

- янгын сүндерү җиһазлары һәм инвентарь сатып алу;
- торак пункт эчендәге юлларны төзекләндерү;
- чишмәне төзекләндерү

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Урсай авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** _________________ **Н.А. Гатина**